РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.09.2026 Буа шәһәре № 319/Бк/к

ТР, Буа муниципаль районы, Карлы авыл җирлеге, Карлы авылы, Муса Җәлил ур., 66 адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:14:140201:25 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында» 2007 елның 14 маендагы 5-16 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. ТР, Буа муниципаль районы, Карлы авыл җирлеге, Карлы авылы, Муса Җәлил ур., 66 адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:14:140201:25 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны 2026 елның 22 сентябренә билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

1) Шакирҗанов Ленар Рәфыйк улы-Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе.
2) Еремеев Илдар Фәрид улы – Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары (килешү буенча).
3) Мифтахов Рәмис Рәис улы – Карлы авыл җирлеге башлыгы. (килешү буенча).
4) Хәмидуллин Рифат Ринат улы – Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары.
5)Гыйльфанов Ринат Мансур улы-архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы.
6) Таканаева Анастасия Анатольевна –«Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе (килешү буенча).

3. ТР, Буа муниципаль районы, Карлы авыл җирлеге, Карлы авылы, Муса Җәлил ур., 66 адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:14:140201:25 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты буенча гавами тыңлауларны түбәндәге адрес буенча уздырырга:

- 422433, Татарстан Республикасы, Буа районы, Карлы авылы, Татарстан урамы, 66 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы 9:30 сәгатьтә.

4. Гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2007 елның 14 маендагы 5-16 номерлы карары белән расланган Буа муниципаль

районында гавами тыңлаулар турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә уздырырга.

5. Фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә, шулай ук чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин:

- 422433, Татарстан Республикасы, Буа районы, Карлы авылы, Татарстан урамы, 66 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы 9:30 сәгатьтә. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты - 22.09.2026 ел. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздырган вакытта язма рәвештә яисә телдән бирелергә мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына:

-халыкка гавами тыңлаулар уздыру башлануы турында Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырып хәбәр итәргә: http://buinsk.tatarstan.ru, һәм авыл җирлегенең гавами тыңлауларда катнашучыларны күрсәтелгән мәгълүматка керә алуны тәэмин итә торган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән :

1) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүматны һәм аңа мәгълүмати материалларны, гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышының яисә җыелышларының датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүматны;

2) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмат һәм мондый проектка мәгълүмати материаллар исемлеге;

3) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект буенча гавами тыңлауларны үткәрү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат;

4) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициясен яисә экспозицияләрен ачу урыны, датасы турында, мондый проектның экспозициясен яисә экспозициясен үткәрү сроклары турында, күрсәтелгән экспозицияләрне һәм экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат;

5) гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар кертү тәртибе, срогы һәм рәвеше турында мәгълүмат;

- ТР, Буа муниципаль районы, Карлы авыл җирлеге, Карлы авылы, Муса Җәлил ур., 66 адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:14:140201:25 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектын һәм аңа мәгълүмати материалларна Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырырга;

- ТР, Буа муниципаль районы, Карлы авыл җирлеге, Карлы авылы, Муса Җәлил ур., 66 адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:14:140201:25 булган җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында карар проекты экспозициясен түбәндәге адрес буенча 2026 елның 09 сентябернен 10.09.2026 елның 22 сентябренә кадәр ачырга һәм үткәрергә:

- 422433, Татарстан Республикасы, Буа районы, Карлы авылы, Татарстан урамы, 66 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы 9:30 сәгатьтә экспозицияне эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 гә кадәр карарга мөмкин. Экспозиция эше барышында экспозициягә килүчеләргә консультация бирү, гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект турында мәгълүмати материаллар тарату оештырылырга тиеш;

- гражданнарның һәм вазыйфаи затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

7. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетына

- Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://buinsk.tatarstan.ru.

- гавами тыңлауларга әзерлекне, гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын билгеләнгән сроклар буенча уздыруны тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләүне һәм рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://buinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: https://pravo.tatarstan.ru/npa_msu/buinsk/oms/ispolkom.htm. урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән законлы көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Л.Р.Шакирҗанов